

17-18 августа Санкт Петербург шәһәрендә «Аулак ой-корәш» проекты нда катнаштык. Санкт-Петербургта «Аулак ой – корәш» тобәкара проекты – зыялылар ярышы иде. Проекта 4 команда катнашты. Командабызнын составы Айлина Юнир кызы Абузярова (Лэмберәнен 2 мәктәбендә татар һәм рус телләре укыта), татар теле укытучылары - Равза Мукаддяс кызы Юмаева (Пензятка урта мәктәбе), Луиза Низаметдин кызы Смакаева (Кривозерье урта мәктәбе), Фазия Фәрит кызы Боярова (Черемиш топ мәктәбе), Радель Руслан улы Байбеков белән Ратмир Равиль улы Карабанов (Черемеш егетләре). Чаранын программасы боек татар шагыйре Габдулла Тукайнын тормыш һәм ижат юлына багышланган иде.

Ярышта Мордовиянен Лэмберә районы Балтач командасы белән корәште. Йолалар буенча Балтач командасы беренче булса, безнен команда Габдулла Тукай ижаты буенча алда булдык. Нәтижәдә без «Аулак ой – корәш» тобәкара проекты призёрлары булып кайттык. Шулай ук программада тvләvле торле кызыклы экскурсияләр оештырылган иде. Командабыз исеменнән «Юлдаш» газетасы аша спонсырларыбызга – Мордовия госсобрание депутаты Валерий Александрович Корнишинга, Лэмберә предпринимательләре - Лэмберә авылынын хозтовары кибете директоры Радмир Альбун улы Аюпов белән Лэмберәдә пластиковые окна оешмасынын житәкчесе Данис Хайдар улы Казаевка, Абдулламалик Асаинов хазрәткә рәхмәтебезне белдерәсе килә. Аларнын ярдәме булмаса, Мордовия командасы бу чарада катнаша алмас иде, чонки Санкт Петербург кvп акча таләп итvче шәһәр.

**Равза ЮМАЕВА**